Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

# КАРАР №LIV-4

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 5 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алына торган муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында

“Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы Күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы Күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) арендаторлар – кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгатеннән соң җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның апрель-июнь айлары өчен аренда түләүләрен мондый арендаторлар тәкъдим иткән срокка кичектерүне, 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча кичектерелгән аренда түләүләрен түли башлауны күздә тоткан өстәмә килешүләр төзүне;

б) әлеге карар үз көченә кергән көннән алып өч эш көне эчендә арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге пунктның "а" пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-

sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны.

2. Билгеләргә:

аренда түләүләрен түләүне кичектерү Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага торышы буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча түләнмәгән бурычы булмаган арендаторларга – кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә;

әлеге карарның 1 пунктындагы "а" пунктчасы нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель-июнь айлары өчен аренда түләвен һәм аны тигез өлешләр белән 2020 һәм (яисә) 2021 елларда аренда шартнамәсендә каралган срокларда түләүне, шулай ук аренда шартнамәсен вакытыннан алда өзгәндә кичектерү бирелә торган аренда түләүләре суммасын бер тапкыр түләүне күздә тотарга тиеш.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Ф.М.Вафинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов